ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

№ 13 Иске Урыссу ав. 05.06.2024 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
«Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставына
өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Конституциясе, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2005 елның 21 июлендәге «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында»гы 97-ФЗ санлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Конституциясе, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советының 2024 елның 18 апрелендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Урыссу авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында"гы 5 санлы карары, 2024 елның 29 маендагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар протоколын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2024 елның 3 июнендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Урыссу авыл җирлеге советының карар проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге Советының 2023 елның 10 ноябрендәге 28 санлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 2023 елның 6 декабрендәге дәүләт теркәве RU165433102023001 санлы булган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына (алга таба - Устав) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Уставның 7 маддәсендәге 1 пунктының 12 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләр хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

1.2. Уставның 38 маддәсендәге 1 пунктының 27 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яисә) челтәр басмасы учреждениесе;»;

Уставның 55 маддәсендәге 1 пунктының 10 пунктчасының 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләр хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;

1.4. Уставның 61 маддәнең 3 пунктын түбәндәге эчтәлекле 13 пункт белән тулыландырырга:

«13) яллаучы вәкилгә (эш бирүчегә) 2007 елның 02 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы Федераль законның 15.2 маддәсендә каралган анкетадагы белешмәләрнең үзенә мәгълүм булган мәгълүм үзгәрешләр турында язма рәвештә хәбәр итәргә, моңа яллаучы (эш бирүче) вәкил карары буенча үзгәргән белешмәләр керми (алга таба - анкетадагы белешмәләр).»;

1.5. Уставның 80 маддәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«80 маддә «Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе»

1. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла торган муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючы булып тора торган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 2013 елның 17 декабрендәге ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән яисә «Ютазы таңы» («Ютазинская новь») (Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан (Роскомнадзор) 2011 елның 7 декабрендәге ЭЛ № ФС 77-47613 санлы федераль хезмәт тарафыннан бирелгән вакытлы матбугат басмасында);

2) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә “Рәсми Татарстан” дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru электрон адресы буенча урнаштыру;

3) түбәндәге адреслар буенча урнашкан җирлекнең торак пунктлары территориясендә мәгълүмат стендларында урнаштыру: Иске Урыссу авылы, Совет урамы, 16в йорт, административ бина; Байлар авылы, Тукай урамы, 41 йорт, мәдәният

йорты бинасы; Какылы-Күл урамы, Елга урамы, 18А йорт, авыл клубы бинасы; Исмәт тимер юл разъезды бистәсе, Болын урамы, 2 йорт, мәгълүмати стенд; Акса-Күл бистәсе, Урман урамы, 1 йорт, мәгълүмати стенд.

3. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталыннан файдалана алуын тәэмин итү өчен, Иске Урыссу авылы, Совет урамы, 16в йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пункты эшли.

4. Җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган муниципаль норматив хокукый актлар, килешүләр аларны имзалаган көннән алып 10 көн эчендә, таратуы федераль закон белән чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, халыкка игълан ителә.

5. Җирлек Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге маддәнең 1 өлешендә күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар әгәр актның үзе тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса, имза салынган көннән үз көченә керә.

7. Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның доменнарын һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турында белешмәләрне күрсәтеп, муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне, халыкка игълан итү (рәсми бастырып чыгарылудан тыш) гамәлгә ашырыла торган вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге җирлек башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән гомуми игътибарга җиткерелә.».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталының челтәр басмасында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга (2014 елның 17 декабрендәге ЭЛ ФС77-60244 санлы ММЧны теркәү турында таныклыгы).

4. Әлеге карар 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 44 маддәсенең 8 өлешенә ярашлы рәвештә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Әминова